ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында» 174-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында» 174-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 15 апреле
№ 608-VII ДС

проект

Татарстан
Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында

### 1 статья. Әлеге Законның җайга салу предметы

1. Әлеге Закон эш бирүчеләргә махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота билгеләү буенча мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турындагы законнар Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең тиешле нигезләмәләренә нигезләнә һәм федераль законнардан һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларыннан, Татарстан Республикасы законнарыннан һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларыннан тора.

### 2 статья. Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) квота – эш бирүче эшкә урнаштырырга тиешле махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш бирүче хезмәткәрләренең уртача исемлектәге саныннан процентларда билгеләнгән эш урыннары саны;

2) махсус хәрби операциядә катнашучылар:

махсус хәрби операция барышында, Россия Федерациясе территориясенә коралллы бәреп керүне кире кагу буенча, Россия Федерациясе дәүләт чигендә һәм махсус хәрби операция уздырыла торган районнарга якын Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә коралллы провокация барышында бурычларны үтәгән (бурычларны үтәүдә катнашкан, бурычларны үтәүдә ярдәм иткән, бурычларны үтәүне тәэмин итү өчен җибәрелгән), хәрби хәрәкәтләр ветераннарына караган затлар;

махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче оешмалар белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләре булган), хәрби хәрәкәтләр ветераннарына караган затлар.

**3 статья. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота билгеләү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы һәм хезмәткәрләр саны 200 кешедән артып киткән эш бирүчеләргә махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота хезмәткәрләрнең уртача исемлектәге санының 1 проценты күләмендә билгеләнә.

2. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота исәпләү максатларында эш бирүченең хезмәткәрләре саны, эш бирүченең Россия Федерациясендәге башка субъектларда урнашкан вәкиллекләре, филиаллары һәм башка аерымланган структур бүлекчәләре хезмәткәрләрен исәпкә алмыйча, хезмәткәрләрнең узган квартал өчен уртача исемлектәге санынннан чыгып билгеләнә.

3. Россия Федерациясенең башка субъектында урнашкан эш бирүченең Татарстан Республикасы территориясендәге вәкиллекләренә, филиалларына һәм бүтән аерымланган структур бүлекчәләренә махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота әлеге Закон нигезендә эш бирүченең үткән квартал өчен мондый вәкиллекләре, филиаллары һәм башка аерымланган структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең исемлектәге уртача санынннан чыгып билгеләнә.

4. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота исәпләнгәндә махсус хәрби операциядә катнашучылар категориясенә кертелгән хезмәткәрләр биләгән эш урыннары саны һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $351^{7}$ статьясы нигезендә хезмәт шартнамәләренең гамәлдә булуын туктатып тору чорына махсус хәрби операциядә катнашучыларга сакланган эш урыннары саны исәпкә алына.

5. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота исәпләү максатларында эш бирүче хезмәткәрләре санын исәпләгәндә вакланма санын түгәрәкләү киметү ягына тулы күрсәткечкә кадәр башкарыла.

6. Эш бирүче махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәүдән азат ителә:

1) эш бирүче инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе һәм ул оештырган оешма, шул исәптән устав (җыелма) капиталы инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе кертеменнән торган хуҗалык ширкәте һәм җәмгыять булып торган очракта;

2) эш бирүче бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип танылган һәм конкурс производствосы ачылган очракта;

3) эш бирүче тарафыннан хезмәткәрләр санын яки штатын кыскарту чаралары үткәрелгән чорда;

4) Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәт органнарында яраклы эш эзләү максатларында теркәлгән, эш бирүче тарафыннан белдерелгән вакансияләргә карата һөнәри-квалификация таләпләренә туры килүче махсус хәрби операциядә катнашучылар исәпкә алынмаган очракта;

5) эш бирүче хезмәткәрләре саны махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота билгеләнми торган хезмәткәрләр санына кадәр кимеелгән очракта.

7. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар

хезмәткәрләренең исемлектәге уртача санына федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә вазыйфага сайлау, тиешле вазыйфаны биләүгә конкурс буенча сайлау, вазыйфага билгеләп кую яки вазыйфага раслау юлы белән биләнә торган вазыйфалар кертелми.

8. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**4 статья. Эш бирүчеләрнең хокуклары һәм бурычлары**

1. Эш бирүчеләр хокуклы:

1) Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарыннан хезмәт базары торышы турында мәгълүматны, шулай ук әлеге Законда каралган хокукларны һәм бурычларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка мәгълүматны түләүсез алырга;

2) Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан җибәрелә торган махсус хәрби операциядә катнашучыларга, аларны алга таба мәҗбүри эшкә урнаштыру шарты белән, өстәмә һөнәри белем бирү өчен Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына заявкалар җибәрергә.

2. Эш бирүчеләр бурычлы:

1) махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квотаны үтәргә;

2) махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә урнаштыру өчен булдырыла торган яки бүлеп бирелә торган эш урыннары турында белешмәләр бирелгән локаль норматив актлар кабул итәргә;

3) хисап аеннан соң килә торган айның 10ысына кадәр ай саен халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүмат урнаштырырга.

3. Эш бирүче тарафыннан махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота үтәлеше түбәндәгеләр булган очракта тәэмин ителә:

1) эш урынына махсус хәрби операциядә катнашучы белән турыдан-туры эш бирүчедә төзелгән хезмәт шартнамәсе;

2) махсус хәрби операциядә катнашучы һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы тарафыннан расланган форма буенча махсус хәрби операциядә катнашучыны эшкә алу өчен квота билгеләнгән эш бирүче белән махсус хәрби операциядә катнашучыны эшкә урнаштыру турында килешү төзегән башка оешмалар (инвалидларның иҗтимагый берләшмәләрен һәм алар төзегән оешмаларны, шул исәптән устав (җыелма) капиталы инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе кертеменнән торган хуҗалык ширкәтләрен һәм җәмгыятьләрне кертеп) (алга таба – башка оешма) арасында төзелгән хезмәт шартнамәсе (алга таба – килешү);

3) махсус хәрби операциядә катнашучы һәм килешү төзегән индивидуаль

эшкуар арасында төзелгән хезмәт шартнамәсе;

4) оешмалар төркеме өчен башка оешма яки индивидуаль эшкуар белән килешү төзү ярдәмендә махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота, махсус хәрби операциядә катнашучы һәм башка оешма, индивидуаль эшкуар арасында төзелгән хезмәт шартнамәсе үтәлешен тәэмин итүче оешма белән түләүле хезмәтләр күрсәтү шартнамәсе яки башка шартнамә.

4. Эш бирүченең инвалид булган махсус хәрби операциядә катнашучы белән төзелгән хезмәт шартнамәсе булган очракта, махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квотаның һәм «Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнгән инвалидларны эшкә алу өчен квотаның үтәлеше бер үк вакытта тәэмин ителә.

**5 статья. Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) махсус хәрби операциядә катнашкан хәрби хәрәкәтләр ветераннары өчен эш белән тәэмин итүгә өстәмә гарантияләр булдыру максатларында эшләнде.

Закон проекты белән махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган, 200 кешедән артык хезмәткәре булган эш бирүчеләргә хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан 1 процент күләмендә квота билгеләү тәкъдим ителә.

Закон проекты шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы һәм квота билгеләнгән эш бирүче белән махсус хәрби операциядә катнашучыны эшкә урнаштыру турында килешү төзегән башка оешма арасында төзелгән хезмәт шартнамәсе булган очракта эш бирүченең билгеләнгән квотаны үтәвен күздә тота.

Эш бирүче түбәндәге очракларда квотаны үтәүдән азат ителә:

әгәр ул инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе һәм ул төзегән оешма булса;

ул бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип танылган һәм конкурс производствосы ачылган булса;

аның тарафыннан хезмәткәрләр эштән күпләп азат ителгән яки азат ителү планлаштырылган булса;

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында яраклы эш эзләү максатларында теркәлгән, эш бирүче тарафыннан белдерелгән вакансияләргә карата һөнәри-квалификация таләпләренә туры килә торган махсус хәрби операциядә катнашучылар исәпкә алынмаган очракта;

хезмәткәрләр саны квота билгеләнми торган хезмәткәрләр санына кадәр киметелгән булса.

Россия Федерациясенең кайбер төбәкләрендә махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота билгеләү карала торган закон актлары кабул ителгән һәм гамәлдә.

Татарстан Республикасында яңалык Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган, хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны 200дән артык булган 875 эш бирүчегә кагылачак (Татарстанстат мәгълүматлары буенча). Закон проектын гамәлгә ашыру махсус хәрби операциядә катнашучыларны уңышлы эшкә урнаштырырга ярдәм итәчәк.

**«Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү башкарма хакимиятнең халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге вәкаләтле органының махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен эш урыннарын квоталау тәртибе һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүмат урнаштыру тәртибе турында акт кабул итүен таләп итәчәк.

**«Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанслау таләп итми.